КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1289

2024 елда «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында шикәр диабетын ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр диабетлы пациентның хәлен контрольдә тоту өчен авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын җиһаз белән өстәмә тәэмин итү (яңадан тәэмин итү) чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында шикәр диабетын ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр диабетлы пациентның хәлен контрольдә тоту өчен авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын җиһаз белән өстәмә тәэмин итү (яңадан тәэмин итү) чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1289 нчы
карары белән расланды

2024 елда «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында шикәр диабетын ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр диабетлы пациентның хәлен контрольдә тоту өчен авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын җиһаз белән өстәмә тәэмин итү (яңадан тәэмин итү) чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында шикәр диабетын ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр диабетлы пациентның хәлен контрольдә тоту өчен авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын җиһаз белән өстәмә тәэмин итү (яңадан тәэмин итү) чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында шикәр диабетын ачыклау һәм элек ачыкланган шикәр диабетлы пациентның хәлен контрольдә тоту өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы авыл халкына һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын җиһаз белән өстәмә тәэмин итү (яңадан тәэмин итү) чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидия (алга таба – субсидия) (алга таба – бюджет акчасы) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Бюджет акчасы, технологик характеристикалары эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең гликирацияләнгән гемоглобин анализаторларына өстенлек тәкъдим ителүне исәпкә алып, медицина оешмаларын гликирацияләнгән гемоглобин анализлаторлары белән җиһазландыруга (яңадан җиһазландыруга) тотыла.

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Бюджет акчасын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, иң чик финанслау күләмнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң,иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм

расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә гликирацияләнгән гемоглобин анализаторларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

гликирацияләнгән гемоглобин анализаторларын сатып алуга дәүләт контрактлары (килешүләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (килешүләр) шартлары нигезендә акча күчерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисаплылык, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык урнаштыра.

8. Бюджет акчасын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирелә.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

_______________________